**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕРӘШ- ШУРАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ IV ЧАКЫРЫЛЫШ LIII УТЫРЫШЫ**

# КАРАР

24 март 2025 ел

№ 83

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Керәш-Шуран авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 07 маендагы 21-ТРЗ номерлы 25, 26 статьялары, «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районың Керәш-Шуран авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 31 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Керәш-Шуран авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Керәш-Шуран авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын ун елга расларга (1 нче кушымта).

2. Әлеге карарны, бермандатлы сайлау округлары схемасын да кертеп, аның график сурәте белән бергә (2 нче кушымта), әлеге карар кабул ителгәннән соң 5 көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән, шулай ук Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (muslumovo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Керәш-Шуран авыл җирлегенең Керәш-Шуран, Каенсаз, Ташъелга, Приют-Шуран, Татар Шураны авыллары территорияләрендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча халыкка җиткерергә:

Керәш-Шуран ав., Үзәк ур., 6А йорт (мәдәният йорты бинасы);
Каенсаз ав., Звездная ур., 50Б йорт (китапханә бинасы);
Ташъелга ав., Урман ур., 31 йорт (авыл клубы бинасы);
Приют-Шуран ав., Садовая ур., 2 й. (шәхси йорт);
Татар Шураны ав., Мәктәп ур.,1 (шәхси йорт).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Керәш-Шуран авыл җирлек Башлыгы Сафиуллин Р.Г.

Мөслим муниципаль районы
Керәшен авыл җирлеге Советы
утырышы карарына 1 нче кушымта
Татарстан Республикасы 2025 елның
24 мартындагы 83 номерлы

СХЕМА
Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Керәш Шуран авыл җирлеге " муниципаль берәмлегенең вәкиллекле органына депутатлар сайлаулар буенча сайлау округлары

| № п/п | Сайлау округының исеме, № | Сайлау округына керүче торак пунктлар | Сайлау округына керүче урамнар исеме | сайлау округына керүче йортларның номерлары | Сайлаучылар саны |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Таш-Елга № 1 | Таш-Елга авылы | Урман ур | №№ 37 – 63<br>№№ 2 – 56 | 42 |
| 2 | Таш-Елга № 1 | Таш-Елга авылы | Урман ур. | №№ 1 – 35 | 42 |
| | | Каен-Саз авылы | Звездная ур. | № 25 – 59<br>№ 42 – 52 | |
| 3 | Каен- Саз № 3 | Каен-Саз авылы | Звездная ур. | №№ 1 – 23<br>№№ 2 – 40 | 39 |
| | | Приют-Шуран авылы | Комсомол ур. | тулысынча | |
| 4 | Приют-Шуран № 4 | Приют-Шуран авылы | Бакча ур. | тулысынча | 40 |
| | | Кряш-Шуран авылы | Узәк ур. | №№ 1 – 17<br>№№ 2 – 12 | |
| 5 | Кряш-Шуран № 5 | Кряш-Шуран авылы | Узәк ур. | №№ 19 – 43 | 44 |
| | | | Яшел ур. | тулысынча | |
| 6 | Кряш-Шуран № 6 | Кряш-Шуран авылы | Узәк ур. | №№ 14 – 36 | 45 |
| | | Татар Шураны авылы | Мәктәп ур. | №№ 1 – 29<br>№№ 2 – 34 | |
| 7 | Тат.Шуран № 7 | Татар Шураны авылы | Мәктәп ур. | №№ 31 – 49<br>№№ 36 – 58Б | 46 |

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Керәш-Шуран авыл җирлеге Советының 2025 елның 24 мартындагы 13 номерлы карарына 2 нче кушымта

Керәш-Шуран авыл җирлегенең бермандатлы сайлау округлары схемасының график сурәте
Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы

